ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Тњбђн Мђтђскђ авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**« 31 » гыйнвар 2020 ел** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Кырлай» авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Кырлай» авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләргә 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә 6124 сум 86 тиен күләмендә бәя куярга һәм 2020 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Башкарма комитетының "01"апрель 2019 ел, №5 "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Кырлай» авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында" карарын 2020 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип таныրга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Сиражетдинов

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Иске Кырлай авыл җирлеге
Башкарма комитетының
"31" гыйнвар 2020ел, №1
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Кырлай» авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләрнең БӘЯСЕ**

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4055,55 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка илтү | 489,78 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1579,53 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Иске Кырлай авыл җирлеге
Башкарма комитетының
"31" гыйнвар 2020ел, №1
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Кырлай» авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләрнең БӘЯСЕ**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне төрү | 220,39 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3835,16 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка илтү | 489,78 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 1579,53 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |